**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ________________ ПР-181 от 26.09.2024 КАРАР № _________

Иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Уразай авыл җирлеге, Куян авылы, Үзәк урам, 57 йорт - «клублар (мәдәният йортлары)» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә индивидуаль торак йортлар (Ж1) төзелеше зонасында, 1994 кв. м мәйданлы 16:04:210201:591 кадастр номеры булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлауларны билгеләргә.

2. Иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

1) Шәймәрдәнова Гүзәлия Сәлимҗан кызы
2) Галиахметов Айнур Кәрим улы
3) Зәйнетдинов Булат Рифат улы
4) Миргалимова Дифинә Даим кызы

3. Уразай авыл башкарма комитетына иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручыга җирле үзидарә турындагы законнар, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) үткәрү 28.09.2024 елга кадәр тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5.Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, https://aktanysh.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.Т.Демидовка йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов